**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлегенең Югары Лоҗы торак пунктында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**14 ноябрь 2025 ел** **№ 2**

"Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 20.03.2025 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциясендә катнашучылардан, аларның гаилә członнарыннан һәм махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаиләләреннән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Бигеш авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (торак пункт эчендә юлларны ремонтлау һәм салу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 88 кеше кертелгән, җыенында 48 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе буенча гражданнар җыенында катнашучыларның 44 кеше тавыш бирде;

“Каршы” дип 4 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Югары Лоҗы торак пунктында гражданнар җыены үткән, гражданнар җыененың нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциясендә катнашучылардан, аларның гаилә членнарыннан һәм махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаиләләреннән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Бигеш авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (торак пункт эчендә юлларны ремонтлау һәм салу).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге мәгълүмат

стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге башлыгы** ____________________ **И.Р.Вәлиев**